ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки
муниципаль районы
Юхмачы авыл җирлеге
Советы

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Юхмачинского сельского поселения
Алькеевского муниципального района

Адресы: 422885, ТР, Әлки районы,
Юхмачы авылы, Болын урамы ,1а
Тел./факс 8(84346) 74-224

Адрес:422885, РТ, Алькеевский
район, с. Юхмачи, ул.Луговая д.1а
тел./факс 8(84346) 74-224

**РЕШЕНИЕ** **Юхмачы авылы** **КАРАР**

2022 елның 21 июне 56№

2022 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Юхмачы авыл җирлеге милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) турында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 50 һәм 51 статьялары, 85 статьясындагы 8 пунктның 4 пунктчасы, 2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Юхмачы авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Юхмачы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.2022 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Юхмачы авыл җирлеге милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Юхмачы авыл җирлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фараз планын үтәү өчен кирәкле әзерлек чараларын башкару максатларында "Әлки муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы" МКУнә мөрәҗәгать итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми www.alkeevskiy.tatarstan.ru/uhmachisp.htm сайтында һәм Россия Федерациясенең «Интернет» челтәрендәге рәсми www.torgi.gov.ru. сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының бюджет, салым һәм финанс, җирле җыем, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль районы
Юхмачы авыл җирлеге башлыгы Р. А. Сәлахов

**2022 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Юхмачы авыл җирлеге милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы ( программасы)**

## 1 нче бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2022 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Юхмачы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы ( программасы)(алга таба - муниципаль мөлкәт) 2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Юхмачы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эшләнде.

1.2. 2022 елда муниципаль милекне хосусыйлаштыру муниципаль милек белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрүгә, кучемсез милек объектларын тотуга инвестицияләр җәлеп итүгә, муниципаль милекне сатудан бюджет дефицитын каплау чыганакларын булдыруга юнәлдерелгән.

1.3. 2001елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында»гы 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль милекне хосусыйлаштыруны аукционда сату юлы белән башкару күздә тотыла.

## 2 нче бүлек. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль милек

2.1. 2022 елда муниципаль казнадагы һәм Әлки муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган оешмалар карамагында булмаган муниципаль милек хосусыйлаштырыла.

2.2.Хосусыйлаштыруга планлаштырыла торган муниципаль милек исемлеге:

| т/б № | Милекнең атамасы һәм характеристикасы | Адрес (урнашу урыны) | Файдалануга тапшыру елы, (чыккан елы) | Хосусыйлаштыруның фаразланган вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Автотранспорт чарасы CHEVROLET NIVA,212300-55 идентификация номеры (VIN) X9L212300E0497195 җиңел | Татарстан Республикасы, Әлки муниципаль районы, Юхмачы ав., Болын ур., 1а й. | 2013 | 3,4 квартал |

## 3 нче бүлек. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруны мәгълумати тәэмин итү муниципаль мөлкәт

3.1. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру турындагы мәгълүматны оператив рәвештә бирү һәм Юхмачы авыл җирлеге башкарма комитеты әлеге прогноз планын үтәү барышында, рәсми мәгълүмат чыганакларыннан тыш, бүтән массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәтеннән дә файдаланырга хокуклы.